| Республика Татарстан | | Татарстан Республикасы |
|---|---|---|
| Исполнительный комитет Менделеевского муниципального района | | Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

06.07.2023 Менделеевск ш. № 403/1

Экология экспертиза объектының
проект документациясе турында,
шул исәптән аның әйләнә-тирә мохиткә
йогынтысын бәяләүнең беренчел
материалларын да кертеп, иҗтимагый
фикер алышулар үткәрү турында

«Экология экспертизасы турында» 1995 елның 20 ноябрендәге 174-ФЗ номерлы, «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законнарга таянып, Россия Федерациясе табигать ресурслары һәм экология министрлыгының 2020 елның 1 декабрендәге 999 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты

К А Р А Р  Б И Р Ә:

1. Экология экспертизасының проект документациясен, шул исәптән әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны бәяләүнең башлангыч материалларын да кертеп, түбәндәге объект буенча иҗтимагый фикер алышулар оештырырга һәм уздырырга: «206 км обходчик йорты - КПКУ 221 км Киенгоп - Н.Чаллы. ВК ПТУС “Строительство»

2. Иҗтимагый фикер алышуларны үткәрү вакытын - 2023 елның 11 августында 14:00 сәгатьтә, үткәрү урынын: Менделеевск шәһәре, Фомин урамы, 7 йорт адресы буенча Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының актлар залын билгеләргә.

3. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән мәсьәлә буенча иҗтимагый фикер алышуларны оештыру һәм уздыру өчен түбәндәге составта комиссия төзергә:

Искаков А.Ф. - Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары, комиссия рәисе;

Готин Ю.А. - Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының инвестиция һәм инфраструктура үсеше идарәсе» муниципаль автоном учреждениесе башлыгы;

Хәбиров Р.З. - Татарстан Республикасы «Менделеевск муниципаль районының инвестиция һәм инфраструктура үсеше идарәсе» муниципаль автоном учреждениесенең баш архитекторы хезмәте архитекторы;

Антоновская Н.И. - Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының мөлкәти һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе (килешү буенча).

4. Әлеге карарны Менделеевск муниципаль районының «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында https://Mendeleevsk.tatar.ru/ урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары А.Ф. Искаковка йөкләргә.

Җитәкче Р.Р.Искәндәров

Килештерелде

Юридик бүлек башлыгы Е.С.Царева

Башк. Хәбиров Р.З.
8(85549)2-01-99